**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**города Азнакаево**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай**
**муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. (85592) 7-24-83, факс (85592) 7-20-31
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» сентябрь 2019 ел № 281

«ТР Азнакай МР, Мәрҗәни урамы буенча түбән басымлы газ үткәргечне күчерү» линия объектына Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясен планлаштыру һәм межалау проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясына таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10. 2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 28 статьясы, Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Азнакай шәһәрендә ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. «ТР Азнакай МР, Мәрҗәни урамы буенча түбән басымлы газ үткәргечне күчерү» линия объектына Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясен планлаштыру һәм межалау проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Татрстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башлыгы ачык тыңлаулар үткәрүнең инициаторы булып тора.

3. Билгеләргә:

- уздыру вакыты: 2019 елның 5 сентябреннән 2019 елның 07 октябренә, 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

- үткәрү урыны: Азнакай ш., Ленин ур., 14;

- фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2019 елның 7 октябренә кадәр - Азнакай ш., м. Солтангалиев ур., 24 нче йорт адресы буенча Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлегенә (эш көннәрендә 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр) кертелә ала.

4. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетына:

- гамәлдәге законнар һәм әлеге карар нигезендә билгеләнгән срокларда «ТР Азнакай МР, Мәрҗәни урамы буенча түбән басымлы газ үткәргечне күчерү» линия объектына Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясен планлаштыру һәм межалау проекты буенча ачык тыңлауларны әзерләргә һәм уздырырга;

5. Кушымта нигезендә, Азнакай муниципаль районы территориясен планлаштыру һәм межалау проекты турында фикер алышу буенча ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү буенча эшче төркем составын расларга.

6. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм

Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык М.З. Шәйдуллин

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Башлыгы
карарына кушымта
« ___ »________2019 ел №_____

«ТР Азнакай МР, Мәрҗәни урамы буенча түбән басымлы газ үткәргечне күчерү» линия объектына Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре территориясен планлаштыру һәм межалау проекты буенча ачык тыңлауларны әзерләү һәм уздыру буенча эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| *Эшче төркем рәисе:* | |
| Шәмсетдинов А.Х. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| *Эшче төркем секретаре:* | |
| Әюпова Р.Р. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече (килешү буенча) |
| *Эшче төркем әгъзалары:* | |
| Солтанов М.И. | Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Шәрәфетдинова С.Ф. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Миндубаева Л.Ф. | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Мөгтәсимов Р.Р. | Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәр Советы депутаты, «Азнакай муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү Департаменты» МУП директоры (килешү буенча) |
| Алчина Э.А. | Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы депутаты, «Универсал-Азнакай» ИК ЖЧҖ генераль директоры, совет әгъзасы (килешү буенча) |